Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлеге Сәләнгеш авылында
гражданнар җыены КАРАРЫ

«16» ноябрь 2024 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә», 2024 елның 16 ноябрендә түбәндәге сораулар белән узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде:

1. 2025 елда үзара салым акчаларын кертү һәм тоту турында.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә: җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 301 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 161 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

1. Беренче мәсьәлә: 2025 елда үзара салым акчаларын кертү һәм тоту турында гражданнар каравына чыгарыла торган мәсьәлә текстына үзгәрешләр кертү турында. 2025 елда үзара салым кертү турында гражданнар җыенында каралуга чыгарылган мәсьәләгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә: «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш авыл җирлеге Сәләнгеш авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан тыш, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, СВОда катнашучылардан, 90 яшь тутыручылардан тыш, 2025 елда 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү;
- янгынга каршы резервуарларны (янгын сулыкларын), янгын пирсларын төзү, ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- ремонт, коймалар кору, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү.

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашучы 156 кеше тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен 5 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлеге Сәләнгеш авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәләләр буенча кабул ителгән карарларны танырга:

- 2025 елда үзара салым акчаларын кертү һәм тоту турында.

3. Халык җыенының нәтиҗәләрен «Интернет «мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш авылының мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлегенең әлеге карарын Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыены рәисе: А.Н. Пинин

Сәләнгеш авыл җирлеге башлыгы: А.Н. Пинин